Безнең белән үткән балачак күңелегездә мәңге калачак!

Көмеш кыңгырау

№75-76 (1116)
18 ноябрь
2006 ел

1996 елның 1 гыйнварыннан чыга башлады

Татар балалары газетасы

Үрнәк алыйк

Айгизгә күз тимәсен

Бу язмамда сезне үзем җитәкләгән сыйныф укучысы Айгиз Гыймазетдинов белән таныштырырга телим. Айгизгә 13 яшь, ә ул инде 9 яшеннән ... трактор йөртә. Кечкенә генә гәүдәсе белән "Беларусь" тракторын да, көчле ДТ тракторын да иярли ул. Тракторда бөтен төр эшне башкара: җирне сукалый, тырмалый, язын бәрәңге утырта, көзен бәрәңгене казыта. Бакчадан трактор белән бәрәңге, чүгендер, чүп ташу кебек эшләргә күрше-күлән Айгизнең мәктәптән кайтканын дүрт күз белән көтеп тора.

Гаиләдә ир бала, гадәттә, әтисеннән үрнәк алып үсә диюләре дөрестер. Айгизнең әтисе Назыйм да, нәрсәгә тотынса, шуны булдыра: механизатор-шофер да ул, эретеп ябыштыручы, электрик, ташчы ... Өстәвенә әле оста гармунчы да. Шуңа күрә Таулык авылында үткәрелгән чараларның берсе дә Гыймазетдиновлар гаиләсеннән башка узмый. Бу гаилә районның "Балкыш" фестивалендә, иҗат концертларында да катнаша. Шулай, Айгиз хезмәттә генә түгел, сәнгатьтә дә әтисеннән үрнәк ала: матур җырлый, курайда уйный. 2005 елда ул Түбән Кама шәһәрендә үткәрелгән "Ватан" халык иҗаты фестивалендә катнашып, диплом белән бүләкләнде. Ә районкүләм "Балкыш" фестивалендә җырлап грамотага лаек булды. Сыйныфта, мәктәптә уздырылган бер чарадан да читтә калмый Айгиз. Күптән түгел уңыш бәйрәменә А.С. Пушкинның "Поп һәм аның эшчесе Балда" әкиятен сәхнәләштердек, анда Айгиз хезмәт сөюче Балда ролен искиткеч оста башкарды. Иң сәнгатьле сөйләүче ул безнең. Хезмәттә һәм сәнгатьтә генә түгел, укуда да алдынгы ул: 1нче чиректе "4" һәм "5" билгеләренә генә тәмамлады. Иҗат эшенә дә вакыт таба Айгиз. Узган ел без аның белән "Туган ягым Татарстан" дип исемләнгән төбәкара иҗади эшләр конкурсында катнаштык. Айгизнең язма эше 3нче призлы урынга лаек булды. Чаллы шәһәрендә узган бүләкләү тантанасында әтисе дә катнашты аның. Минем белән бергә ул да улы өчен горурлык хисләре кичерде. Өстәвенә, бу ихлас бәйрәмдә Айгизнең оста җырчы һәм тракторчы да булуы ачылды бит. Әйе, егет кешегә 70 төрле һөнәр дә аз дип, нәкъ менә безнең Айгиз турында әйтәләр инде. Бөтен төр техниканы йөртә белгән Айгиз батарейкалардан үзе хәрәкәтләнүче әйберләр ясарга да ярата әле. Кем белә, бәлки киләчәктә авыл хуҗалыгы өчен катлаулы техник җиһазлар ясаучы конструктор булыр ул. Әйбәт җырчы да чыгар иде аннан. Ә нигә булмасын? Бөек җырчыларыбыз Илһам Шакиров, Зөһрә Сәхәбиева, композитор Рубис Зарипов белем алган мәктәптә укый бит ул. Танылган җырчы Алмаз Ишморатов та аның туган авылы Таулык егете бит. Ә Айгиз үзе исә инженер-механик булырга хыяллана. Исәбе - югары белем алып, туган җирдә хезмәт итү. Шундый тырыш, хезмәт сөючән, кечкенәдән техника җене кагылган егетнең хыялы, һичшиксез, тормышка ашар. Үз эшенең чын остасы булыр ул. Айгиз кебек эш сөюче, туган җирен яратучы яшьләребез күбрәк булса, киләчәгебез, һичшиксез, матур булыр безнең.

Мин Айгиз кебек укучым булу белән хаклы рәвештә горурланам. Аңа 12нче ноябрьдә 13 яшь тулды. Аны сыйныфтагы барлык укучылар исеменнән туган көне белән котлыйм. Аңа укуда, хезмәттә, сәнгатьтә зур уңышлар, нык сәламәтлек телибез. Барлык хыялларың тормышка ашсын, Айгиз!

Зәкия ШӘМСЕТДИНОВА,
Тукай районы, Теләнче Тамак мәктәбе укытучысы.

Подписка - 2007

"Көмеш кыңгырау" - чын дустым!

"Көмеш кыңгырау" - чын дустым,
Хак юлга озатучым,
Дөнья серен ачучым,
Шатлык өстәп торучым.

Мавыктыргыч язмаларың,
Әдәпкә чакыралар.
Синең дуслар күптер инде,
Мин калышмам алардан.

Син киләсе көнне мин
Зарыгып көтеп алам.
Почта тартмасыннан күзне
Һичбер мизгелгә алмам.

Көмешсылу киңәшләрен
Чыгармыйм һич исемнән.
Синең белән бергәләшеп
Атлыйм дуслык иленнән.

Якын дустым - "Көмеш кыңгырау",
Дуслар булып калыйк, гел шулай!

Ләйлә СӘЛАХОВА,
Яңа Чишмә районы,
Шахмай урта мәктәбе,
6нчы сыйныф.

Газетабызга язылу бәяләре: Тукай, Мөслим, Әгерже, Минзәлә, Актаныш районнары һәм Чаллы шәһәре өчен (00015 индексы буенча) - 114 сум 54 тиен, калган шәһәр һәм районнарга 31700 индексы буенча - 144 сум 60 тиен.

Бәхет

Яшь кешеләр барысы да
Җирдә эзли бәхетне.
Әмма алар бәхет диеп
Беләләр шул тәхетне.

Кушымта:
Бәхет бит ул - сәламәтлек,
Бәхет ул - тату гаилә.
Бик тырыш һәм сабыр булсаң,
Бәхет үзе дә килә.

Бәхетемне таптым диеп
Яшәсәләр байлыкта.
Ул кеше бик ялгышадыр:
Бәхет бит ул - саулыкта.
Куш.

Акча дигәне дә кирәк,
Әмма бел син чамасын.
“Акча” диеп намусыңа
Куркыныч янамасын!
Куш.

Рөстәм МӘРДӘНОВ,
Алабуга районы, Морт мәктәбе, бичы сыйныф.

Дуслар, бәлки Рөстәмнең бу шигыренә көй язучы да табылыр?!

Ак юл

Ишеп-ишеп ап-ак карлар ява,
Җанга рәхәт, чиста һава.
Ап-ак карлар ерып алга барам,
Мин үземә яңа юл ярам.

Алып керсен мине ап-ак юлым
Ачышларга, шигъри дөньяга.
Ап-ак бөртек булып, әй җемелдәп,
Яшәр идем мин бу дөньяда.

Бөртек-бөртек карлар яусыннар,
Хыялларым чынга ашсыннар.

Ирек ФӘЙЗРАХМАНОВ,
25нче мәктәп, 7 “В” сыйныфы.

Арчам

“Арча ягы ямьле, Тукай ягы!”
Күпме җырлар сиңа җырлана.
Җырларыңны көйләп, күпме халкың
Чит җирләрдә сагынып моңлана.

Күпме батыр кыз һәм улларыңа
Хәер-фатихаңны бирдең син.
Хезмәт сөйгән тырыш игенчеләр белән,
Читекчеләр белән данлы син.

Шул даныңны югалтмыйча, Арчам,
Алга атлавыңны дәвам ит.
Миңа да бир хәер-фатихаңны,
Зур уңышлар миннән өмет ит.

Айгөл ДӘУЛИЕВА,
Арча районы, Түбән Аты мәктәбе, 11нче сыйныф.



Дусларыбыз шигъри күңелле



Куянкай

Әй куян, куян,
Кечкенә генә,
Бик йомшак кына,
Бик куркак кына.

Ике колагы
Озынкай гына,
Аягы җиңел-
Мамыккай гына.

Койрыгы тора
Өрпелеп кенә,
Мыегы тора
Бөркелеп кенә.

Борыны кечкенә,
Бөгелгән генә,
Ирене дә ярык,
Бүленгән генә.

Күзләре чалыш,
Түгәрәк кенә,
Ул йөри-йөри
Чүгәләп кенә.

Тавышы-теле юк,
Шундый шым гына,
Посып тыңлавы-
Шыпыртын гына.

Айнур ШӘМСЕТДИНОВ,
24нче мәктәп, 4 “А” сыйныфы.

Туган ягым

Синдә тудым, синдә гомер кичтем,
Синдә үтте бала чакларым.
Сезнең белән генә дөнья ямьле,
Туган җирем, туган якларым.

Яратам мин сине, туган авылым,
Сокланамын синең халкыңа.
Күңелемдә туган шигырьләрем
Булыр күбрәк синең хакыңда.

Чулпан ХӘНИПОВА,
Саба районы, Юлбат авылы.

Тукай шигырьләрен укы

Авырлыктан йөрәк куркып калса,-
Күңелеңдә сагыш урын алса-
Тукай әсәрләрен кулыңа ал,
Кыйммәт фикерләрен җаныңа сал.

Чишеп булмас бер мәсьәлә туса,
Җаныңны гел авырттырып торса-
Тукай шигырьләрен кулыңа ал,
Җавап табып шунда алырсың ял.

Нахак сүзләр йөрәгеңне әрнетсәләр,-
Бәгырьсезләр күңелеңне рәнҗетсәләр-
Кайгылардан башыңны имә,
Тукай шигырьләрен көйлә.

Тукай моңнарына үтеп керсәң,
Һәр юлына күңелеңне бирсәң-
Шунда аңларсың син Тукай көчен,
Аның әсәрләре - безнең өчен!

Алина ШАКИРОВА,
54нче гимназия, 9 “А” сыйныфы.

Малайлар, сезнең өчен!

Галстук кына димәгез...

Ир-егет өчен галстук - киемнең бик тә мөһим өлеше. Хатын-кыз өчен сумка кебек. Галстук, күлмәк һәм костюм бер-берсенә төсе буенча килешергә тиеш. Кара костюм, ак күлмәк һәм бик ачык булмаган галстук классик кием санала. Истә тот: әгәр дә галстук һәм костюм бизәкле тукымадан булса, күлмәгең бер төсле генә булырга тиеш. Әгәр дә син киң җилкәле икән, эре бизәкле киң галстук сайла. Озын буйлыларга вак бизәкле тар галстук тәкъдим ителә. Галстугың тырпаеп тормасын өчен аны күлмәгеңә каптырма белән беркетеп куй. Галстугың ошамый? Ачык төстәге (артык чәчәкле булмасын) муен яулыгы белән алыштыр, галстук-күбәләк тә килешер, тик күлмәгеңнең якасы күтәртмә булсын.

Исеңдә тот:

•Аяк киемен гадине һәм ябыкны сайла. Ялтырап тора торган ботинкаларны фрак яисә смокинг белән генә кияләр.

•Кичәгә яңа туфлиләр кимә: аягыңны кырса, күңел ача алмыйча интегерсең.

•Костюмың һәрвакыт төймәләнгән булсын: йөргәндә дә, басып торганда да. Бер капламлы ике генә төймәле булганда өскесен , өч сәдәф булганда уртадагысын гына эләктерәләр. Ике капламлы костюм булса, бар төймәләрне дә каптырырга кирәк.

•Аягыңны аякка куеп утырырга ратасың икән, оекбашыңнан аягың күренеп торырлык булмасын.

•Хушбуйга коенма.

Аңа ак кәләпүш килешә

Бу араларда татар халкы үзенең Мөдәррисе - чын шагыйре булуына тагы бер кат сөенеп алды. Соңгы вакытларда газета-журналлар аның турында күп яздылар - шагыйрьгә 60 яшь тулды. Президентыбыз фәрманы белән "Халык шагыйре" исеме дә биределде Мөдәррис Әгъләмовка!

Матбугатта чыккан язмалардан шуны белерлек булды: Мөдәррис Әгъләмов безнең якташыбыз! Чаллыдан ерак булмаган Зәй районы, Түбән Биш авылында туып үскән. Чаллы район газетасы каршындагы әдәби түгәрәккә дә йөргән әле. Университетта укыган елларында ук үз уй-фикерен, хискичерешен фәкать үзенчә: яңгыравыклы матур итеп, уйлы кешене уйга салырдай итеп әйтеп бирә белгән шагыйрь буларак танылa. Аны Хәсән Туфан күреп ала, Сибгат Хәким дә үз итә. Шигъриятебезнең шушы ике аксакалы яшь шагыйрьдә үз дәвамчыларын күреп, сөенеп-горурланып бу турыда башкаларга да гел әйтеп киләләр.

Матбугаттан укып тагы шуны да белдек: рухы-җаны белән фәрештәләр янында, җиде кат күк өстендә яшәп гадәтләнгән шагыйрь, тәне-бәдәне өчен уңайлыкларны кайгыртмаган да. Озак еллар язучыларның Аккош күлендәге буш, *салкын дачаларында* көн күргән. Үз торак җире дә булмаган. Соңгы елларда аңа квартира да биргәннәр. Үзен аңлардай, яратырдай пары да табылган. Шагыйрә Нәҗибә Сафина белән икәү икән алар.

Хәзер үзем белгән Мөдәррис Әгъләмов турында язарга тырышып карыйм әле.

... Аның белән мине Фәния Хуҗәхмәтова таныштырды ("Татар мөселман календаре"н чыгаручы, танылган журналистны белмәүчеләр юктыр инде ул?!). Ул чакта без Фәния белән икебез дә Казан Дәүләт университеты абитуриентлары, ягъни студент булырга хыялланып имтихан биреп йөрүчеләр идек.

- Мөдәррис килгән. Әйдә, таныштырам, - беркөнне Фәния миңа шулай ди.

- Мөдәррис Әгъләмовмы? Шагыйрьме? - дип ышанмыйча кат-кат соравым хәтердә.

- Әйе, әйе! Нәкъ үзе! - дип Фәния күрше бүлмәгә алып керде.

Ямь-яшел зур күзләр. Озын кара керфекләр. Кара тут йөз. Куе, килешле чәч. Чибәр булып, яшь булып әле дә күз алдында тора ул. "Шигырь укы әле!" дип бәйләнгәнбездер инде.

- Теләсә кайда, теләсә ничек шигырь укый алмыйм, - диюе истә калган.

... Аннан соң, Казанда эшләү дәверендә, Мөдәррис Әгъләмовны еш күрергә, аралашырга туры килде. Үткен сүзле икәнлегенә, экспромт белән генә кызыклы рифмалар әйтеп куюына да шаһит булгаладым.

... Бервакыт "Татарстан яшьләр"ендә Мирхәтим исемле егет эшләп алды. Минем каршыда гына утыра иде. Беркөнне Мөдәррис килеп керде дә, яңа егеттән исемен сорады.

"Мирхәтим" дигәнне ишеткәч, "Барыбыз да мир хотим, исемеңне әйт син миңа!" ди шагыйрь.

Егет исемен кабатлагач, "Я - Мударрис, я тоже мир хочу" дия-дия чыгып китте ул.

... Мөдәрриснең сөйкемле сөяге бар. Минем күңелемә дә ул балаларымның исемнәрен хәтерләве, очрашканда үз итеп аларның хәлләрен сорашуы белән якын кеше, үз кеше булып керде. Кызым әле туган гына, исемен дә яңа куйган гына идек. Ниндидер документ артыннан редакциягә килгән идем, Мөдәррис очрады.

- Нәфисә ничек анда? Бик еламыймы? - ди бу.

- Исемен каян белдең соң әле ? - дим.

- Шундый матур исемле кыз дөньяга тусын да, белмичә дә кал, имеш! - диде ул мине шаккатырып һәм сөендереп. Еллар үтеп, Нәфисәнең үзен күреп: "Исеме җисеменә туры килгән бит кызыңның", дип тагы бер шатландырды.



... "Көмеш кыңгырау" исемле балалар газетасы дөньяга тугач та, битараф калмады Мөдәррис Әгъләмов. Иң беренчеләрдән булып ул котлады. Балалар өчен иҗат итүче Казан язучылары, шагыйрьләре һәм газетабыз арасында арадашчы, күпер булды. Яңа әсәрләрен алып, автографлары белән безгә җибәреп торды.

- Күп нәрсәгә яңача карыйсыз. Яңача эшлисез, - дип мактап күңелне дә күтәрә иде.

Боларның барысы өчен дә ихлас рәхмәт сиңа, олы җанлы шагыйрь!

... Соңгы елларда газета-журналлар Мөдәррис Әгъләмовның кулдан бәйләнгән ак кәләпүш белән төшкән портретын бирделәр. Ул кәләпүшнең дә безгә бәйле тарихы бар. Шуңа да бераз язып әле. Шагыйрьнең 55 яшь тулган көнен Чаллыда да зурлап үткәргән идек. "Ни бүләк итим икән үзенә?" дип баш вата торгач, дустым - кул остасы Фәния Гәрәевага: "Ак җептән кәләпүш бәйләп бир әле", - дим. Тиктормас Фәния аны ике көндә бәйләп бирде. Кәләпүшне: "Матур шигырьләр тулы башыгызга уңай йогынты ясасын, әйбәт шигырьләр тагы да туып торсын!" дигән теләк белән, зал тулы тамашачы алдында тапшырган идем. Әле үзем: "Киярме икән соң ул аны?" дип икеләнеп тә куйган идем.

Кигән бит әле менә! Күңеленең аклыгына тәңгәл килгәнгәме, ничек *килешә аңа ак кәләпүш!*

... Бу юлларны язганда үземә дә әзерәк уңайсыз: мактанам бит. Тик бу, мактанырга ярый торган очрактыр, мөгаен ...

Халык шагыйре - Мөдәррис Әгъләмов, бераз соңарып булса да олы бәйрәмең белән котлыйм сине! Үз исемемнән һәм син хуплаган-яраткан "Көмеш кыңгырау"ны укучы балалар исеменнән.

Нәсимә САДЫЙКОВА.

Мөдәррис Әгъләмов

Мин табышмак чишәм

Яралганмын кара туфрагымнан,
Идел-судан, халык җырларыннан;
Ак яулыклы татар карчыгының
Яргаланып беткән кулларыннан.

Яралганмын әнкәм көлтә итеп
Бәйләр өчен җыйган учмалардан;
Көлтәләрдән учма булып кына
Безгә килеп җиткән кыйссалардан.

Яралганмын җил-давыллар узып
Исән калган агач башларыннан;
Чиркәүләргә нигез булып яткан
Бабамнарның кабер ташларыннан.

Яралганмын халык иҗат иткән
Табышмактан, әйе, табышмактан ...
Әткәм хыялланып эзләп йөргән,
Җавап итеп әнкәм мине тапкан.

Тапкан табышмакка җавап итеп,-
Шулай тапкан әткәм эзләгәнен...
Тик барыбер бер табышмак булып
Калган минем һәрбер күзәнәгем.

Балам, бәгърем, диеп

Толымыңны яраттым да,
Агарттым да, әнкәем,

Адашмаган кеше юл эзләми,
Юл табылмый әле тиз генә ...
Ялгышларым белән җирдән китсәм,
Үз ялгышым калсын үземә.
Яман юлда йөр, дип, начар бул, дип,
Үстермәгән мине әнкәем;
Байрак итеп йөртәм: «Халык юлы-
Иң изге юл», - диеп әйткәнен.

Оекбаш

Гыйнвар суыклары дөрли тышта,
Үз-үземә әйтәм:
Тоеп бас!
Җанда - ил җылысы,-
Аягымда-
Әбкәм бәйләп биргән оекбаш.

Әйтерсең лә, бала чакларымның
Нечкә хисләреннән үрелгән;
Мин йөгергән сары идәннәрдән
Нәни бәрән булып йөгергән.
Яшел болыннардан йөгергәндер-
Үләннәрдән куәкән җылы бар ...
Ничә күрдем:
Носкиларын атып,
Аякларын уып елыйлар.

Җилбәзәклек кинәт җилгә оча,
Читкә оча капрон оеклар ...
Елатыр да әле, уйлатыр да,
Байтак биетер бу суыклар.

... Җанда - ил җылысы,
Аягымда-
Әбкәм бәйләп биргән оекбаш.
Бернәрсә дә бәлки, аның кадәр
Бу суыкта җанны җылытмас.

Көн дә бер әкият

Ялгандырмы, чындырмы,
Бабам сөйләде моны.

Борын заманда түгел,
Әле япь-яшь чагында,
Умарталар тоткан ул
Түреш дигән авылда.

Умартада, билгеле,
Бал кортлары булган, ди.
Кәрәзләре бал белән
Тулып кына торган, ди.

Авылның малайларын
Ул бал белән сыйлаган.
Саран булу гадәтен
Бабай бер дә сөймәгән.

Ә малайлар бабамны
Шундый хөрмәт иткәннәр.
Берәр йомышы булса,
Йөгереп килеп җиткәннәр.

Тезелешеп утырып,
Әкият тыңлаганнар.
Табышмаклар әйтешеп,
Зирәклек сынаганнар.

Шулай беркөн бабамның
Бер күче аерылган да,
Бакчасыннан туп-туры
Элдергән, ди, урманга.

Ярый әле урамда
Малайлар уйнап йөргән.
Кара болыттай күчне
Бөтенесе дә күргән.

Ә күч киткәч шәп түгел ...
Анысын белә бабай.
- Баш исән булсын, - дигән,
Борчылмаган ул алай.

Тик малайлар бу хәлгә
Битараф калмаганнар.
Эшнең гаять тә җитди
Икәнен аңлаганнар.

Кулларга тубал тотып,
Күч артыннан чапканнар.
Тәннәре сыдырылган,
Кычытканнар чакканнар.

Малайлар һаман барган,
Ниһаять, күч арыган.
Бер юкә агачының
Нәкъ очына сарылган.

Кортлар хәйләкәр икән,
Әзер оя тапканнар.
Юкәнең тишегенә
Кергәннәр дә качканнар.

Малайлар ни эшләсен,
Юкәгә тамга салып,
Буш кул белән кайтканнар
Урманнан арып-талып.

Бабам аларны күргәч,
Шатланып туймаган, ди.
Малайларны кызганып,
Бал белән сыйлаган, ди.

- Күч артыннан кем чапсын,
Бәхеткә сез исән, - ди.
- Нигә рөхсәт бирдем
Мин карт юләр, исәр, - ди.

- Ярый адашмагансыз,
Күчне дә тапкансыз, - ди.
Кайда икәнен белеп,
Тамгалап кайткансыз, - ди.

Мөҗәһит

Аю ничек баллы булган

Гөлия МӨХӘММӘТГАЛИЕВА,
Саба районы, Сатыш авылы, 15 яшь.

... Шулай көннәр үткән, ди.
Бал вакыты җиткән, ди.
Малайлар җыелышып,
Күч карарга киткән, ди.

Янәсе ул ояны
Чит-ят итмәгәннәрме?
Безгә уңайсыз, диеп,
Ташлап китмәгәннәрме?

Барсалар ... ни күрсеннәр,
Ул агачның башыннан
Төшеп килә бер аю,
Үзе чиный, кашына ...

Чәбәләнә мескенкәй,
Түзәлми корт чагуга.
Малайларны күргәчтен
Курыккан ул тагы да.

Ә малайлар, малайлар
Нишләргә дип торганда,
Телгә килгән бу аю:
- Әй, сез минем урманда
Нәрсә эзләп йөрисез?
Ник урманда сез мине
Хуҗа диеп белмисез?

Лап-лоп атлап барган да
Күлгә кереп чумган ул.
Йөзләгән корт чагудан
Тик шулай котылган ул.

Булатка бу Аюхан
Ай, кызганыч тоелган.
Мескенкәйне җәлләүдән
Сөмсерләре коелган.

Шунда бер корт Булатның
Түшенә килеп кунган.
Кешеләрчә тел белән
Безелдәргә тотынган:
- Умартачы бабайга
Без-з-з дән сәлам әйтегез-з.
Үзегез-з-з дә, адашмый,
Туры кайтып җитегез-з-з.
Без-з-з беләбез-з-з аюның
Балны бик яратканын.
Хәзер күреп торабыз-з-з
Су төбендә ятканын.
Караклар - без-з-знең дошман,
Аларны һич сөймибез-з-з.
Бал белән намуслыны,
Тырышларны сыйлыйбыз-з-з.
Сез-з-з аюга әйтегез,
Куркып, суда ятмасын.
Киресенчә, ул без-з-зне
Дошманнардан сакласын.
Әгәр без-зне тыңласа,
Бал белән дә сыйларбыз-з-з.
Ул без-знең хуҗа диеп,
Бар киеккә сөйләрбез-з-з.

Камышлар арасыннан
Аю торган ишетеп.
Ул сүзләрне аңлаган
Үзенә зур эш итеп.

- Бал белән сыйласалар,
Мин күнәм, күнәм, - дигән.
- Башка сезнең агачка
Беркайчан менмәм, - дигән.

- Сакларммын кешеләрдән,
Сакларммын һәр киектән.
Ә сез хәбәр бирерсез
Оягыздан, биектән.

Шулай татулашканнар,
Бер-берсен аңлашканнар.
Бал бабай кортларына
Яңа юллар ачканнар.

Чөнки алар биектән
Гел күзәтеп торганнар.
Бабайның бал кортларын
Баллы җиргә борганнар.

Малайлар табигатькә
Бер зыян да салмаган.
Шешенеп беткән аю
Шул хәлләрне аңлаган.

- Әй малайлар, сез, - дигән,
- Гел курыкмагыз миннән.
Тик беркемгә әйтмичә
Чыгып китмәгез өйдән.

Малайлар белән Аю
Дуслыкка күпер салган.
Үзем дә белмим менә:
Кайсы чын, кайсы ялган ...

Көмеш кыңгырау

"Көмеш кыңгырау"ны гамәлгә куючы: "ТАТМЕДИА" массакүләм коммуникацияләр буенча Татарстан Республикасы агентлыгы.

Баш мөхәррир
Нәсимә САДЫЙКОВА

Рәссам -
Фаил Ислам

Язмаларны компьютерда җыючы һәм урнаштыручы-
Эльвира Салихова
Гүзәлия Фәйзуллина

"Көмеш кыңгырау" газетасы массакүләм мәгълүмат чаралары һәм мәдәни мирасны саклау өлкәсендәге законнарны үтәүгә күзәтчелек итүче федераль хезмәтенең Идел буе идарәсендә ПИ №ФС7-3729 саны белән теркәлде.

БЕЗГӘ КИЛЕГЕЗ, ХАТЛАР ЯЗЫГЫЗ: 423802, Чаллы шәһәре, ГЭС бистәсе, Гидротөзүчеләр урамы, 10нчы йорт, 429нчы бүлмә. "Көмеш кыңгырау" газетасы редакциясе. E-mail:komesh_k@List.ru

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:

71-50-22 - баш мөхәррир.
71-49-94 - операторлар, тәрҗемәче.
71-50-24 - баш хисапчы, баш мөхәррир урынбасары, рәссам.

Редакциягә килгән хатлар рецензияләнми, кире кайтарылмый.
"Көмеш кыңгырау"дан алынган язмаларның чыганагын күрсәтү мәҗбүри.

р/с 40703810810000000449
в ЗАО ГКБ "Автоградбанк"
г.Н.Челны
к/с 30101810100000000748
БИК 049240748. ИНН 1650048918

Җаваплылыгы чикләнгән "Глагол" ширкәте типографиясендә басылды. Язмаларның эчтәлеге һәм аларны газетада урнаштыруның сыйфаты өчен типография җавап бирми.
Атнага икe тапкыр чыга.
Индекс 31700
"Көмеш кыңгырау" тиражы - 3057

Басарга кул куелды 17.11.2006

© "Көмеш кыңгырау", 2006 ел